ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга, «аерым» сүзен төшереп калдырырга;

2) преамбулада «муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирә»

сүзләрен «муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына Россия Федерациясе тарафыннан тапшырыла торган беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган муниципаль район составына керүче җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында, муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының түбәндәге дәүләт вәкаләтләре бирелә (алга таба шулай ук – дәүләт вәкаләтләре):

1) Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлек бюджетына муниципаль район бюджетыннан субвенция исәпләү методикасы (әлеге Законга 1 нче кушымта) нигезендә җирлек бюджетына субвенция исәпләү;

2) муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән муниципаль районның вәкиллекле органының тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) муниципаль район бюджеты турындагы карары белән расланган бүлү нигезендә субвенцияләр бирү.»;

4) 2 статьяның исемендә «аерым» сүзен төшереп калдырырга;

5) 4 статьяның 1 өлешендә «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә, «күләмен билгеләү» сүзләрен «исәпләү» сүзенә алмаштырырга;

6) 6 статьяда:
а) 1 өлешнең 3 пунктында «тапшырылган» сүзен төшереп калдырырга;
б) 2 өлештә:
1 пунктта «дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген башкаруга» сүзләрен «дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән субвенцияләрнең исәбен алырга һәм аларның максатчан файдаланышын тәэмин итәргә;»;

3 пунктта «тапшырылган» сүзен төшереп калдырырга, «финанс чараларын» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

6 пунктта «финанс чараларын» сүзләрен «субвенцияләрне, шулай ук матди чараларны» сүзләренә алмаштырырга;

7) 7 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктында «гамәлгә ашыруын» сүзләре татарча текстта үзгәрешсез кала, «матди һәм финанс чараларының» сүзләрен «субвенцияләрнең һәм матди чараларның» сүзләренә алмаштырырга;

8) 9 статьяда:

а) исемендә «Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын» сүзләрен «Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта:

«а» пунктчасында:

беренче абзацта «тапшырылган» сүзен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «башкару» сүзен «гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «гамәлгә ашыру» сүзләре татарча текстта үзгәрешсез кала;

«б» пунктчасында «финанс чараларыннан» сүзләрен «субвенцияләрдән» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 пунктның икенче абзацында «башкару» сүзен «гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

9) 10 статьяда:

а) исемендә «Үзләренә тапшырылган дәүләт» сүзләрен «Дәүләт» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

1 пунктта «тапшырылган», «гамәлдәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «вазыйфаи затлары» сүзләреннән соң «дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча законнарны, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

в) 2 өлештә «финанс чаралары» сүзләрен «субвенцияләр» сүзенә алмаштырырга;

г) 3 өлештә «гамәлдәге» сүзен төшереп калдырырга;

10) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

**Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлек бюджетына муниципаль район бюджетыннан субвенция исәпләү методикасы**

1. Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен i-җирлеге бюджетына субвенция күләме (Si) түбәндәге формула белән билгеләнә:

$$Si = (Nосвоб.i + Nсовм.i \times ki) \times Fi,$$

$$ki = tсовм.i / tосвоб.,$$

монда:

Nосвоб.i – i-җирлегендә җирле үзидарә органында даими эшләүче хәрби исәпкә алу хезмәткәрләре саны;

Nсовм.i – i-җирлегендә җирле үзидарә органында беренчел хәрби исәпкә алу эшен өстәмә эш итеп башкаручы хезмәткәрләр саны;

ki – эш вакыты коэффициенты;

tсовм.i – i-җирлегендә җирле үзидарә органында беренчел хәрби исәпкә алу эшен өстәмә эш итеп башкаручы бер хезмәткәргә кирәкле вакыт (елына иң күбе 792 сәгать);

tосвоб. – елдагы эш вакыты нормативы, ул 1980 сәгать тәшкил итә (елдагы 247,5 эш көне һәм көненә 8 эш сәгате тапкырчыгышы);

Fi – i-җирлегендә җирле үзидарә органының бер хәрби исәпкә алу хезмәткәрен тоту чыгымнары.

2. I-җирлегендә җирле үзидарә органының бер хәрби исәпкә алу хезмәткәрен тоту чыгымнары (Fi) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Fi = ЗПi + Ai + Ci + Ti + Ki + КомУi + МЗi,$$

монда:

ЗПi – бер хәрби исәпкә алу хезмәткәре хезмәтенә түләү чыгымнары, хезмәткә түләү фондына тиешле исәпләүләрне дә кертеп;

Ai – бүлмәләрне арендалаган өчен түләү чыгымнары;

Ci – элемтә хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;

Ti – транспорт хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;

Ki – командировка чыгымнары;

КомУi – коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары;

МЗi – җиһаз, инвентарь, оештыру техникасы, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү чыгымнары.»;

11) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр исәпләү методикасы**

1. Әлеге Методика территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру

өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне исәпләү өчен каралган.

2. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме *($S_{общ}$)* түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_{общ} = \sum_{i=1}^{n} Sp_i,$$

монда:

$Sp_i$ – i-муниципаль районы бюджетына бирелә торган субвенция күләме;

n – дәүләт вәкаләтләре бирелгән муниципаль районнар саны.

3. I-муниципаль районы бюджетына бирелә торган субвенция күләме ($Sp_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Sp_i = (Nосвоб_i + Nсовм_i \times k_i) \times F_i,$$

монда:

$Nосвоб_i$ – i-муниципаль районында җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында даими эшләүче хәрби исәпкә алу хезмәткәрләре саны;

$Nсовм_i$ – i-муниципаль районында җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында беренчел хәрби исәпкә алу эшен өстәмә эш итеп башкаручы хезмәткәрләр саны;

$k_i$ – эш вакыты коэффициенты;

$F_i$ – i-муниципаль районында җирлекнең җирле үзидарә органында бер хәрби исәпкә алу хезмәткәрен тоту өчен чыгымнар.

4. I-муниципаль районында даими эшләүче хәрби исәпкә алу хезмәткәрләренең һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органында беренчел хәрби исәпкә алу эшен өстәмә эш итеп башкара торган хезмәткәрләрнең саны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән нормалардан чыгып билгеләнә.

5. Эш вакыты коэффициенты ($k_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$k_i = tсовм_i / tосвоб,$$

монда:

$tсовм_i$ – i-муниципаль районында җирлекнең җирле үзидарә органында беренчел хәрби исәпкә алу эшен өстәмә эш итеп башкаручы бер хезмәткәргә кирәкле вакыт (елына иң күбе 792 сәгать);

tосвоб – елдагы эш вакыты нормативы, ул 1980 сәгать тәшкил итә (елдагы 247,5 эш көне һәм көненә 8 эш сәгате тапкырчыгышы).

6. I-муниципаль районында җирлекнең җирле үзидарә органының бер хәрби исәпкә алу хезмәткәрен тоту өчен чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$F_i = (F_{зп} + F_{аренда} + F_{связь} + F_{трансп} + F_{кр} + F_{ку} + F_{мо}),$$

монда:

$F_{зп}$ – бер хәрби исәпкә алу хезмәткәре хезмәтенә түләү чыгымнары, хезмәткә түләү фондына тиешле исәпләүләрне дә кертеп;

$F_{аренда}$ – бүлмәләрне арендалаган өчен түләү чыгымнары;

$F_{связь}$ – элемтә хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;

$F_{трансп}$ – транспорт хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;

$F_{кр}$ – командировка чыгымнары;

$F_{ку}$ – коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары;

$F_{мо}$ – җиһаз, инвентарь, оештыру техникасы, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү чыгымнары.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты | Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 16 июль
№ 51-ТРЗ